*Яшел Үзән шәһәре «7 нче номерлы мәктәп» нең*

*Татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

***Гатауллина Гөлназ Фәрид кызы***

**Тема:** Җиләк - җимешләр һәм яшелчәләр.

**Сыйныф:** 2нче сыйныфның рус төркемендә кабатлау дәресе.

**Максатлар:**
**Белем бирү максаты:**
1. "Җиләк - җимеш" һәм "Яшелчә" темасына караган төшенчәләрне атый; аларны сөйләмдә куллана белү.
**Үстерү максаты:**

2. Укучыларның сөйләм телен, иҗади фикерләү сәләтен үстерү.

**Тәрбия бирү максаты:**

3. Балаларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну теләген арттыру; сыйныфташларың белән итәгатьле аралаша белү өстендә эшне дәвам итү.

**Дәреснең тибы:** кабатлау (ныгыту) дәресе.

**Җиһазлау:** интерактив такта, компьютер, аудиодиск, тартма, уенчык песи, яшелчә һәм җиләк - җимешләр кәрзине, белемне бәяләү өчен төрле төстәге түгәрәкләр, җиләк рәсемнәре.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру моменты.**

а) уңай халәт тудырып, укучыларны уку эшчәнлегенә мотивлаштыру.

*("Сәлам" җыры яңгырый. Балалар бер-берсен сәламлиләр)*

**II. Уку мәсьәләсен кую.**

*(Җыр яңгырый).* ***(слайд 1)***

- Балалар, җыр нәрсә турында?

- Яшелчә, җиләк - җимешләр турында.

- Әйе, бик дөрес. Димәк, без бүген җиләк - җимеш, яшелчәләр турында сөйләшербез.

Дәресебезнең темасы,  димәк "Җиләк - җимешләр һәм яшелчәләр" була. ***(слайд 2)***

- Ә хәзер дәресебезгә максат куйыйк. Без бүген дәрестә нәрсәләр белербез икән? ***(слайд 3)***

1. Җиләк - җимешләрне, яшелчәләрне кабатларбыз;

2. Алар турында сөйләрбез. Аларның тәмен, төсен атарбыз;

3. Кем нинди җиләк - җимеш яратканын әйтербез.

*(Ишек шакыйлар. Дәрескә "Серле тартма" тотып Мырау керә.)*

**III. Уку мәсьәләсен чишү.**

- Балалар, безгә бүген кунакка кем килде?

- Мырау. ***(слайд 4)***

- Әйе, Мырау. Ул безгә "Серле тартма" белән килгән икән.

- Нәрсә бар икән бу тартмада? *(укытучы карый)*

- Балалар, Мырау сезгә биремнәр алып килгән. Ул сезнең белемнәрегезне тикшерә.

- Әйдәгез әле, 1нче биремне карыйк!

**1.Белем һәм осталыкларны яңа ситуацияләрдә куллану.**

а) Җиләк - җимешләрне һәм яшелчәләрне кәрзингә тутыр. ***(слайд 5,6)***

- Икенче биремгә күчәбез.

б) Ситуатив биремнәр белән эш. ***(слайд 7)***

**IV.Ял минуты.** ***(слайд 8)***

- Ә хәзер ял итеп алабыз. *(Җыр яңгырый, балалар төрле хәрәкәтләр ясыйлар)*

**2. Үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү.**

"Минем турында сөйлә" уены. ***(слайд 9)***

- Балалар, Мырау безгә тагын бер сынау оештырган. Сез кәрзиннән яшелчә, җиләк - җимешләрне алып, аның турында сөйләргә тиеш буласыз.

- Алга таба эшебезне дәвам итәбез. Киләсе бирем:

**3. "Эшлекле төркемнәрдә " эшләү.** ***(слайд 10)***

*(Ике төркемгә бүленеп кроссворд чишү)*

- Ә хәзер тикшереп китәбез. ***(слайд 11)***

Һәр эштән соң укучылар үз-үзләренә бәя бирә, "җиләк" ярдәмендә.

**4. Рәсем буенча эш (монолог эше).**

- Балалар, эшебезне дәвам итеп "Серле тартма"ны ачабыз. Киләсе бирем:

Гаиләдә кем нинди яшелчә ярата? Әйт. ***(слайд 12)***

**V. Рефлексия.** ***(слайд 13)***

1. Рефлексив кабатлау.

- Балалар, без бүген нәрсәләр белдек?

- Кайсы бирем авыр булды?

- Үзегезнең эшчәнлегегезне түгәрәкләр кулланып бәяләгез!

2. Өйгә эш. ***(слайд 14)***

- Балалар, Мырау бит сезгә күчтәнәч тә алып килгән. *(Кәрзин белән алмалар)*

- Яшелчә һәм җиләк - җимешләр витаминнарга бай. Күбрәк витаминнар ашагыз! Авырмагыз!

- Дәрес тәмам, сау булыгыз!